ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 26 июле** **Чистай шәһәре** **№ 417**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы территориясендә бердәм айлык социаль юл билеты һәм айлык бердәм балалар социаль юл билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнар өчен бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы территориясендә бердәм айлык социаль юл билеты һәм айлык бердәм балалар социаль юл билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәреәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 10 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр күчерү срогы - вәкаләтле орган субсидия бирү турында карар кабул иткән көннең унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов